СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

28.08.2025 г.　　　　с. Шеланга　　　　№ 50-265

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының «Шилангы авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» 2005нче елның 17нче ноябрендә кабул ителгән 11нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 80 пункты нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының 2005 нче елның 17 нче ноябрендә кабул ителгән 11 нче номерлы «Шилангы авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 5нче статьясындагы 3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары биләгән җир кишәрлекләренә, гомуми файдаланудагы мәйданнарга, урамнарга, юлларга, паркларга, аллеяларга, яшел утыртмаларга, һәйкәлләргә, бәйрәм чараларын үткәрү урыннарына, спорт объектларына һәм гомуми файдаланудагы башка объектларга карата муниципаль казна учреждениеләре.

Шилангы авыл җирлеге территориясендә җир салымы билгеләү турында» Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советы карарының текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Бу карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Шилангы авыл җирлегенең

мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы Майоров В.В.

Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Советының
28.08.2025 ел №47-260 карарына
1 номерлы кушымта

Шилангы авыл җирлеге территориядә җир салымын билгеләү турында

1 статья. Гомуми нигезләмәләр.
Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлеге нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба – салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.
2 статья. Салым ставкалары.
Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:
1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 %;
Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (әлеге пунктта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш) яисә эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган хосусый торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 %;
3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә, кадастр бәясе һәрберсенең 300 миллион сумнан артып китүче җир кишәрлекләреннән тыш, кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;
4.Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата

5. Башка җир кишәрлекләренә карата 1.5 %.
3 статья. Хисап чоры.
Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы,

икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

4 статья. Салым түләү тәртибе һәм сроклары.

Салым түләүче оешмалар тарафыннан үткән салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча салым түләнергә тиеш. Салым буенча авария түләүләре салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килә торган айның 28 числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш».

5 статья. Салым ташламалары

Салым салудан азат итергә:

1. Граждан күмүләре белән мәшгуль җир кишәрлекләренә карата оешмалар һәм учреждениеләр;
2. Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм инвалидларның тол хатыннары (тол ирләре), 4 һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затларның салым түләүчеләре;
3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары биләгән җир кишәрлекләренә, гомуми файдаланудагы мәйданнарга, урамнарга, юлларга, паркларга, аллеяларга, яшел утыртмаларга, һәйкәлләргә, бәйрәм чараларын үткәрү урыннарына, спорт объектларына һәм гомуми файдаланудагы башка объектларга карата муниципаль казна учреждениеләре.

Җирле бюджеттан финанслана торган бюджет учреждениеләре биләгән җир кишәрлекләренә карата салымның киметелгән ставкасын 0,6% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташламаны, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, бирергә.

Гомуми файдаланудагы 1-3 категориядәге автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата салым түләүгә салым 0,05 %ның киметелгән ставкасын куллану рәвешендә ташлама бирергә.

Бюджет учреждениеләре тарафыннан республика һәм федераль бюджетлардан финанслана торган җир кишәрлекләренә карата, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, салымның киметелгән ставкасын 1% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташлама бирергә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы Майоров В.В.